КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 июль г.Казань № 632

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында» 2016 ел, 9 июнь, 378 нче карары белән расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында» 2016 ел, 9 июнь, 378 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 октябрь, 943 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктта:

беренче абзацта «мәҗбүри тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,» сүзләреннән соң «һәм (яки) җирле үзидарә органнары,» сүзләрен өстәргә, «җирле үзидарә органы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,» сүзләреннән соң «һәм (яки) җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин